КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 19

Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү турында

Балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештырганда оператив нәтиҗәле ведомствоара хезмәттәшлекне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына ведомство норматив хокук актларын бу карарга туры китерергә.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан линия транспорт идарәсенә, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына, Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше имилеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Тимер юл транспорты идарәсенә караган Горький территориаль бүлегенә, Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсенә, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештырганда ведомствоара хезмәттәшлек итүдә катнашырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 19 гыйнвар, 19 нчы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү механизмын билгели.

1.2. Бу Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемнәрен автобуслар белән оештырылган рәвештә йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1177 нче карары (алга таба – 1177 нче Карар), «Россия Федерациясендә туристлык иминлеген тәэмин итүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2017 ел, 3 март, 252 нче карары, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «СП 2.3.3157-14 нче «Балаларның оештырылган төркемнәрен тимер юл транспорты белән йөртүгә карата санитария-эпидемиология таләпләре» н раслау турында» 2014 ел, 21 гыйнвар, 3 нче карары белән расланган СП 2.5.3157-14 нче Балаларның оештырылган төркемнәрен тимер юл транспорты белән йөртүгә карата санитария-эпидемиология таләпләре, Россия Федерациясенең юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча баш дәүләт инспекторы һәм Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибы тарафыннан 2006 елның 21 сентябрендә раслаган Балаларның оештырылган төркемнәрен автомобиль транспорты белән йөртүләрнең санитария-эпидемиология иминлеген һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча методик тәкъдимнамәләр нигезендә эшләнде.

1.3. Бу Тәртипнең төп төшенчәләре түбәндәгеләр:

инициатор – Татарстан Республикасының балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру өчен җаваплы дәүләт оешмалары яки муниципаль оешмалар;

балалар төркемнәре белән юл йөрү – саны сигездән һәм аннан да күбрәк булган балалар төркемнәрен маршрут транспорт чарасына карамаган автобуста аларның законлы вәкилләресез (законлы вәкилләр озатып йөрүче (озатып йөрүчеләр) итеп билгеләнгән яки медицина хезмәткәре (медицина хезмәткәрләре) итеп билгеләнгән очрактан тыш) гамәлгә ашырыла торган оештырылган рәвештә йөртү. Балалар төркемнәре белән юл йөрүгә шулай ук югарыда әйтеп үтелгән автобусларда һәм тимер юл, су һәм һава транспортында йөрүләр керә.

1.4. Инициаторга Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән формадагы иярчен хатка түбәндәгеләрне теркәүне һәм ведомствога

каравы нигезендә Татарстан Республикасының башкарма хакимият органы җитәкчесе адресына килештерүгә җибәрүне тәкъдим итәргә:

юл йөрүгә чыгуны нигезләүне (муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты боерыгын, ведомствога каравы нигезендә Татарстан Республикасының башкарма хакимият органы боерыгын, мәгариф учреждениесенең расланган уку-укыту планы, дәрестән тыш эшчәнлек планы яки, теркәү номерын һәм көнен күрсәтеп, балалар төркемнәре белән юл йөрүне оештыру турындагы боерыгын);

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 ел, 8 ноябрь, ФЗ-259 нчы Федераль закон нигезендә төзелгән фрахтование шартнамәсе – фрахтование шартнамәсе буенча балалар төркемнәре белән оештырылган рәвештә юл йөрүне гамәлгә ашырган очракта;

медицина хезмәткәре турында белешмәләре (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы) булган документ, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсен яки тиешле лицензиясе булган медицина оешмасы яки индивидуаль эшмәкәр белән төзелгән шартнамә күчермәсен – 1177 нче Карарның 12 нче пункты белән күздә тотылган очракта;

Кулланучылар хокукларын саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан билгеләнгән ассортиментлардан азык-төлек продуктлары (коры паёклар, бутылкалы су) җыелмасы исемлеген (өч сәгатьтән дә озаграк юлда булган балалар өчен);

балалар исемлеген (фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда) һәм һәр баланың яшен, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) элемтәгә керү өчен телефон номерын күрсәтеп), билгеләнгән озатып йөрүчеләрнең исемлеген (һәр озатып йөрүченең фамилиясен, исемен, атасының (булганда) исемен, аның элемтәгә керү өчен телефон номерын күрсәтеп), экскурсия хезмәтен күрсәтүне гамәлгә ашыручы туроператор, турагентство яки оешма хезмәткәрләре исемлеген (һәр озатып йөрүченең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда), аның элемтәгә керү өчен телефон номерын күрсәтеп) – алар маршрут программасын үтәүдә катнашкан очракта;

транспорт йөртүче (транспорт йөртүчеләр) турында белешмәләре (транспорт йөртүченең фамилиясен, исемен, атасының исемен, аның телефонын күрсәтеп) булган документны;

мәгариф оешмасы, белем бирүне гамәлгә ашыра торган оешма, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма, медицина оешмасы яки башка оешма җитәкчесе яки юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өчен җаваплы вазыйфаи заты, автобуста балалар төркемнәре белән оештырылган рәвештә юл йөрүне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшмәкәр (алга таба – оешма) яки фрахтлаучы (балаларны утыртуның әлеге тәртибе фрахтование шартнамәсендә булган очрактан тыш) тарафыннан билгеләнгән балаларны автобуска утырту тәртибе булган документны;

түбәндәгеләрне үз эченә алган маршрут программасын:

хисаплап чыгарылган йөртү вакытын күрсәтеп, хәрәкәт итү графигын;

кунакханә хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик зат исемен яки индивидуаль эшмәкәр фамилиясен, исемен һәм атасының

исемен йә йөртүләр оештыруны гамәлгә ашыручы туроператорның реестр номерын күрсәтеп, ял итү өчен тукталышлар урынын һәм вакытын;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Балалар төркемнәрен автобуслар белән оештырылган рәвештә йөртү турында хәбәрнамә бирү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 30 декабрь, 941 нче боерыгы белән расланган хәбәрнамә бирү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенең автобусларда балалар төркемнәре белән оештырылган рәвештә юл йөрү турындагы хәбәрнамәсен (хәбәрнамә бланкысында керү номеры һәм теркәү көне белән); яки Россия Федерациясенең Эчке эшләр министрлыгы территориаль органына караган Юл хәрәкәте иминилеге дәүләт инспекциясе бүлекчәсе автомобиле (автомобильләре) белән автобусларны озатып йөрүне билгеләү турындагы карар күчермәсен;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «СП 2.3.3157-14 нче «Балаларның оештырылган төркемнәрен тимер юл транспорты белән йөртүгә карата санитария-эпидемиология таләпләре»н раслау турында» 2014 ел, 21 гыйнвар, 3 нче карары белән расланган СП 2.5.3157-14 нче Балаларның оештырылган төркемнәрен тимер юл транспорты белән йөртүгә карата санитария-эпидемиология таләпләренә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча Кулланучылар хокукларын саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе органнары хәбәрнамәсен;

«Пассажирлар тормышына, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян салган өчен транспортта йөртүченең гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү турында һәм пассажирларны метрополитенда йөрткәндә салынган мондый зыянны каплау тәртибе хакында» 2012 ел, 14 июнь, ФЗ-67 нче Федераль закон нигезендә Пассажирлар тормышына, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян салган өчен транспортта йөртүченең гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсен;

заказчы (инициатор) һәм туроператор арасында төзелгән хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәне (шартнамә төзегәндә заказчыга (инициаторга) Федераль туристлык агентлыгының рәсми сайтында («туроператорларның бердәм федераль реестры» бүлеге) туроператор турында белешмәләр булу-булмауны тикшерү тәкъдим ителә) – заказчы (инициатор) һәм туроператор арасында төзелгән шартнамә буенча балалар төркемнәре белән оештырылган рәвештә юл йөрүне гамәлгә ашырган очракта.

1.5. Бу Тәртипнең 1.4 нче пунктында күрсәтелгән документлар инициатор тарафыннан адресатка Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында бердәм документ итеп килештерүгә җибәрелә:

1.5.1. Татарстан Республикасының муниципаль оешмалары тарафыннан балалар төркемнәре белән юл йөрүне оештырганда – территориаль принцип нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының тиешле бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре белән килештереп, кушымтада бирелгән форма буенча ведомствога каравы нигезендә Татарстан

Республикасының башкарма хакимият органы җитәкчесе адресына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитетының рәсми бланкында.

Имза куючы сыйфатында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтелә. Кирәк булганда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты җиткәчесе килештерү өчен документны җаваплы хезмәткәргә җибәрә;

1.5.2. Татарстан Республикасының дәүләт оешмалары тарафыннан балалар төркемнәре белән юл йөрүне оештырганда – бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча ведомствога каравы нигезендә Татарстан Республикасының башкарма хакимият органы җитәкчесе адресына Татарстан Республикасы дәүләт оешмасының рәсми бланкында.

Имза куючы сыйфатында Татарстан Республикасының дәүләт оешмасы җитәкчесе (яки җитәкче вазыйфаларын башкаручы зат) күрсәтелә.

1.6. Адресат сыйфатында шулай ук Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (автомобиль транспорты белән юл йөрүне оештырганда), Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Тимер юл транспорты буенча идарәсенә караган Горький территориаль бүлеге (тимер юл транспорты белән Татарстан Республикасыннан читтә юл йөрүне оештырганда), Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан линия транспорт идарәсе (балалар төркемнәре тимер юл, һава һәм су транспорты белән юл йөргәндә) күрсәтелә.

Имза куелганнан соң документ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башкарма комитетында яки ведомствога каравы нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт оешмасында теркәлә.

1.7. Килештерү нәтиҗәләрен һәм хатны адресат алганнан соң документ килештерелгән яки исәпкә алынган дип санала.

Килештерүчеләрнең күрсәтмәләре (аңлатмалары) булганда, алар «күрсәтмәләр» юлында күрсәтелә.

Килештерүче органнарның күрсәтмәләре булганда, документ эшләп бетерү өчен инициаторга кире кайтарыла, бу вакытта, күрсәтмәләрне исәпкә алып, документның яңа версиясен оештырырга кирәк була.

## 2. Документны рәсмиләштерү буенча тәкъдимнәр

2.1. Документларны килештерү өчен тәкъдим ителә торган вакыт – һәр килештерүче ведомство өчен иң күбе бер эш көне.

2.2. Документ инициатор тарафыннан килештерүгә күздә тотыла торган юл йөрүне гамәлгә ашыруга кадәр 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.3. Инициатор юлга чыгучы затларның шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыклары булуын тәэмин итә.

2.4. Инициатор барып җитәргә авыр булган урыннан, су, тау, спелеология объектларыннан һәм башка объектлардан үтә торган һәм тормыш өчен югары дәрәҗәдә риск булуга, туристлар (экскурсантлар) сәламәтлегенә һәм аларның мөлкәтенә зыян салуга бәйле булган туристлык маршрутларын оештырганда Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Россия Федерациясе субъектлары буенча территориаль органнарына хәбәр итүне оештыра.

Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибенә кушымта

Форма

Балалар төркемнәренең Татарстан Республикасы буенча
һәм аннан читтә юл йөрүгә чыгачаклары турында
мәгълүмати хат

Ведомство каравы нигезендә министрлык җитәкчесенә (балалар төркемнәрен йөртү иминлеге өчен җаваплыга)

Кызыксынучы ведомстволарга, күзәтүче органнарга

Сезгә ______________________________________________________________
(оешма исеме)
_____________________________________________________________________
(бару максаты, бару датасы, чара исеме, юл йөрүгә чыгу өчен нигез – боерык, карар, күрсәтмә, расланган уку-укыту планы яки дәрестән тыш эшчәнлек планы)
_______________________________________________ катнашу максатларында,
_____________________________________________________ маршруты буенча
балалар саны ____, озатып йөрүчеләр саны _____ булган балалар төркемнәре белән юл йөрүгә чыгу турында хәбәр итәм.

Балалар төркемнәрен йөртү Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының балалар төркемнәрен имин йөртүләрне оештыру турындагы законнары һәм норматив хокук актлары таләпләре нигезендә оештырыла.

Кушымта: 1 данәдә _____ биттә

Җитәкчесе _______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)